Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Иске Җирекле авылы

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«15» октябрь, 2022 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Тогаево авылы гражданнар җыены

КАРАР БИРДЕ:

1. «2023 елда яшәү урыны буенча Мәләкәс авыл җирлеге Иске Җирекле Калинин авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500(биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

- юлларны ремонтлау;

-янгын сүндерү машинасы өчен гаражны төзекләндерү (төзелеш материаллары, жиһаз сатып алу);

- территорияне төзекләндерү (куркынычсызлыкны, яшелләндерүне һәм кече архитектура формаларын урнаштыруны тәмин итү буенча чаралар комплексы, тышкы реклама һәм мәгълүмат);

- урамнары яктырту;

- өслектәге су бүлү корылмаларын төзү;

- зират территориясен төзекләндерү (материаллар алу, урнаштыру).

2. Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Иске Җирекле авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Иске Җирекле авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мәләкәс авыл җирлеге Башлыгы Ю.П.Васильев